**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб төзү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб төзү турында» 2008 елның 12 июлендәге ПУ-324 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 27 ноябрендәге ПУ-615 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-209 номерлы, 2009 елның 13 ноябрендәге ПУ-605 номерлы, 2010 елның 1 февралендәге ПУ-36 номерлы, 2010 елның 20 августындагы ПУ-546 номерлы, 2011 елның 7 февралендәге ПУ-48 номерлы, 2013 елның 16 декабрендәге ПУ-1233 номерлы, 2014 елның 8 ноябрендәге ПУ-1023 номерлы, 2016 елның 23 гыйнварындагы ПУ-26 номерлы, 2016 елның 13 октябрендәге ПУ-917 номерлы, 2017 елның 20 гыйнварындагы ПУ-39 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы, 2018 елның 3 маендагы ПУ-348 номерлы, 2018 елның 19 декабрендәге ПУ-864 номерлы, 2018 елның 28 декабрендәге ПУ-890 номерлы, 2020 елның 18 мартындагы ПУ-177 номерлы, 2020 елның 11 августындагы ПУ-470 номерлы, 2021 елның 21 гыйнварындагы ПУ-42 номерлы, 2022 елның 24 августындагы ПУ-590 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 5 июнендәге 385 номерлы һәм 2024 елның 3 июлендәге 510 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб (алга таба шулай ук – Штаб) составында:

Штаб составыннан А.Р. Юмангуловны чыгарырга;

Штаб составына Мортазин Айрат Илһам улын – «Түбән Кама җылылык-электр үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорын (килешү буенча) кертергә;

Штаб әгъзасы Э.Р. Галиеваның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасы баш дәүләт торак инспекторы урынбасары»;

б) Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб турында нигезләмәдә:

4 бүлектә:

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы территориясендә Россиянең Бердәй энергетика системасы режимнары белән идарә итү буенча» сүзләрен «Электр энергетикасында оператив-диспетчерлык идарәсе кагыйдәләре нигезендә кабул ителә торган» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацка «һәм (яисә) электр энергиясе белән тәэмин итү бозылуга китергән авария хәлләре нәтиҗәләрен бетерү барышы турында» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтү өчен башка территориаль челтәр оешмасы тарафыннан файдаланыла торган электр челтәре хуҗалыгы объектларында электр энергиясе белән тәэмин итү бозылуга китергән авария хәлләренең нәтиҗәләрен бетерү өчен система барлыкка китерә торган территориаль челтәр оешмасы көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турында карар кабул итү;

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законның $46^4$ статьясындагы 2 пункты таләпләре нигезендә төзелгән электр челтәре хуҗалыгы объектларыннан файдалану тәртибе турында килешүләрдә катнашу (алга таба – электр челтәре хуҗалыгы объектларыннан файдалану тәртибе турында килешүләр);

алар белән электр челтәре хуҗалыгы объектларыннан файдалану тәртибе турында килешү төзелгән территориаль челтәр оешмаларының Штаб катнашында аларга карата электр челтәре хуҗалыгы объектларыннан файдалану тәртибе турында килешүләр төзелгән объектлар турында белешмәләр кертелгән исемлеген төзү яисә аңа төзәтмәләр кертү.»;

түбәндәге эчтәлекле $5.1^2$ пунктын өстәргә:

«$5.1^2$. Гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы көчләре һәм идарә органнары өчен югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимын керткәндә, гадәттән тыш хәлне булдырмау һәм бетерү чараларын кабул итү кысаларында электр энергетикасы объектының (объектларының) эшләвен туктатып торуга бәйле рәвештә электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләүне кертү (алга таба – гадәттән тыш хәлдә электр энергиясен куллану режимын чикләү) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясенең ваклап сату базарлары эшләве, электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү турында» 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы карары белән расланган Электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү кагыйдәләре нигезендә Штаб карары белән гамәлгә ашырыла.

Гадәттән тыш хәлдә электр энергиясен куллану режимын чикләү турындагы Штаб карарында түбәндәгеләр булырга тиеш:

гадәттән тыш хәлне кисәтү һәм бетерү чараларын күрү кысаларында эксплуатацияләү торышын үзгәртү электр энергетикасы объектларын куллану режимын тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләүгә китерәчәк электр энергетикасы объектлары исемлеге (алга таба – исемлек), мондый электр

энергетикасы объектларының диспетчерлык атамаларын һәм аларның милекчеләре яисә законлы башка хуҗалары булган затларны күрсәтеп;

исемлеккә кертелгән электр энергетикасы объектларын эксплуатацияләү торышын үзгәртү кирәклеген нигезләү;

гадәттән тыш хәлдә электр энергиясен куллану режимын чикләүнең таләп ителә торган күләме (МВт), гадәттән тыш хәлдә электр энергиясен куллану режимын чикләү кертү вакыты һәм урыннары;

гадәттән тыш хәлдә электр энергиясен куллану режимын чикләүнең якынча гамәлдә булу вакыты;

гадәттән тыш хәлдә электр энергиясен куллану режимын чикләү кертү турында, шулай ук тиешле электр энергиясе кулланучыларга, катнаш челтәр оешмаларына һәм гарантия бирүче тәэмин итүчеләргә (электр энергиясен сату, электр энергиясе белән тәэмин итә торган оешмаларга) аның гамәлдә булу сәбәпләре һәм күздә тотыла торган дәвамлылыгы турында хәбәрнамә җибәрү сроклары һәм ысулы.

Әлеге пунктның беренче – җиденче абзацлары нигезендә Штаб кабул иткән карар турындагы мәгълүмат мондый карар кабул ителгән вакыттан алып өч сәгатьтән дә соңга калмыйча гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм тиешле дәрәҗәдәге янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә җибәрелә, шулай ук исемлеккә кертелгән электр энергетикасы объектларының милекчеләре яисә башка законлы хуҗалары булган затларга һәм филиалга җиткерелә (исемлеккә кертелгән электр энергетикасы объектлары диспетчерлык идарәсендә яисә филиалның диспетчерлык карамагында булган очраклар).

Штаб карары нигезендә гадәттән тыш хәлдә электр энергиясен куллану режимын чикләү кертелгән кулланучыларга электр энергиясен тапшыруны торгызу гадәттән тыш хәлдә электр энергиясен куллану режимын чикләүне гамәлдән чыгару турындагы Штаб карары нигезендә гамәлгә ашырыла, ул исемлеккә кертелгән электр энергетикасы объектларының милекчеләре яисә башка законлы хуҗалары булган затлар һәм филиал игътибарына (әлеге пунктның сигезенче абзацында күрсәтелгән очракта) мондый карар кабул ителгән вакыттан ике сәгатьтән дә соңга калмыйча җиткерелә.»;

5.3 пунктта «5.1 пунктында» сүзләрен «5.1 һәм $5.1^2$ пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

5.4 пунктның җиденче абзацында «аның нәтиҗәләре» сүзләрен «электр энергиясе белән тәэмин итүнең бозылуына китергән авария хәлләре нәтиҗәләре» сүзләренә алмаштырырга;

5.6 пунктта «аның нәтиҗәләре» сүзләрен «электр энергиясе белән тәэмин итүнең бозылуына китергән авария хәлләре нәтиҗәләре» сүзләренә алмаштырырга;

6.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегенең унберенче абзацында күрсәтелгән алар белән Штаб катнашында электр челтәре хуҗалыгы объектларыннан файдалану тәртибе турында килешү төзелгән территориаль челтәр оешмалары исемлеген төзү яисә аңа төзәтмәләр кертү өчен Штаб утырышы

ел саен агымдагы елның 4 ноябреннән дә соңга калмыйча һәм күрсәтелгән исемлектәге белешмәләргә киләчәктә төзәтмәләр кертү зарурлыгы булганда, агымдагы ел дәвамында җыела.»;

6.4 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«федераль башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына һәм башка затларга алар тарафыннан электр энергиясе белән тәэмин итүнең бозылуын булдырмый калуга юнәлдерелгән чаралар күрү турында тәкъдимнәр кертә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«бер үк вакытта түбәндәге шартларның үтәлүен саклап, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтү өчен башка территориаль челтәр оешмасы тарафыннан кулланыла торган электр челтәре хуҗалыгы объектларында электр энергиясе белән тәэмин итүнең бозылуына китергән авария хәлләренең нәтиҗәләрен бетерү өчен система барлыкка китерә торган территориаль челтәр оешмасы көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турында карар кабул итә:

- «Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законның $46^4$ статьясындагы 2 пункты таләпләре нигезендә система барлыкка китерә торган территориаль челтәр оешмасы һәм территориаль челтәр оешмасы арасында электр челтәре хуҗалыгы объектларыннан файдалану тәртибе турында шартнамә (килешү) төзелү;

- территориаль челтәр оешмасының авария хәлләре нәтиҗәләрен бетерү өчен үз көчләре һәм чаралары булмау яисә алар җитәрлек булмау, бу хакта Штаб утырышында территориаль челтәр оешмасы вәкиле тарафыннан хәбәр ителү;

- авария хәле нәтиҗәләрен бетерүгә система барлыкка китерә торган территориаль челтәр оешмасын җәлеп итү датасына энергия кабул итүче җайланмалары технологик яктан әлеге оешманың электр челтәре хуҗалыгы объектларына һәм (яисә) Татарстан Республикасы территориясендә милекчесе булмаган, милекчесе билгесез яисә милекчесе милек хокукыннан баш тарткан объектларга тоташкан кулланучыларны электр энергиясе белән тәэмин итү бозылу очракларын бетерү зарурлыгы булмау;

электр челтәре хуҗалыгы объектларыннан файдалану тәртибе турында Штаб катнашында килешү төзелгән территориаль челтәр оешмаларының, мондый килешүләр төзелгән объектлар турында белешмәләрне үз эченә алган исемлеген төзи яисә аңа төзәтмәләр кертә.».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ / АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 12 май
№ 358